
# Йорткүлем – туган җирем



# АВЫЛДА КЫШ



**дә,**
**Аяк басты туган ягыма.** **Ай нурында җем-җем**
**киләләр.**
**Кошлар моңнары да кушылмыйлар** **Урамдагы буран**
**тавышлары**
**Салкын кышның иртән таңында.** **Йөрәкләргә үтеп керәләр...**

***А.Шәгәрәева***










- Г.Шәгәрәева

Урманнар, кырларга
Мамык-мамык кар ява.
Күбәләк булып очып
Агач, куакка куна.

Агачлар шәрә калган
Бар җир йокыга талган.
Ята тәмле төш күреп
Кар-юрганга төренеп...
*Г.Насыйбуллина-Низъмәтҗанова*







- А.Шәгәрәева

**Кыш бөек рәссам бит ул,**
**Үзен сурәтли белә.**
**Һәр йорт тәрәзәсендә**
**Ак пейзажлар күренә...** ***Г.Насыйбуллина-Нигъмәтҗанова***



Кая алар шулай ашыга?
Җиргә төшәргәме,эреп бетәргәме?
Шундый сорау туа башыма.

Өлгерерсез җиргә төшәргә.
Ап-ак юрган булып җәелергә,
Биек таулар булып үсәргә...

*А. Шәгәрәева*



# АВЫЛДА ЯЗ




Н.Габбазов


Н.Габбазов



- З. Әхмәтжанова

**Каршымда тау,шундый биек тау бу,
Ничек аңа менеп җитәргә?
Күңелем әйтә сыман:
“Бәхет тавыдыр бу,
Ярамыйдыр менми китәргә”...** ***А.Шәгәрәева***



Юксыну
Күптәнме соң, дуслар, сезнең белән
Йөри идек кичен җырлашып.
Я булмаса кызык өчен генә,
Яшелчәдән кыяр урлашып.

Җәйге челлә, кызу, бигрәк кызу
Тирән күлдә – “роща” астында,
Шау-гөр килеп, сулар коеныш
Ял итә идек дуслар янында.

Кичләр җитсә, яшел тугайлард
Тыңлый идек кызлар җырлав
Яшь күңелләрне дәртләндергә
Тальян гармуннарның моңнары



Үтте алар, дуслар, үтте алар,
Ул яшь чаклар кире кайтмаслар.
Өзгәләнеп, сулар сипсәң дә,
Шиңгән гөлләр чәчәк атмаслар.
1.01.1954 ел Газиз Нургаязов



- З.Әхмәтҗанова

# Авылда җәй



**Алсу таң уяна.**
**Таң ата. Табигать уяна,**
**Җанлана, төнлә тынып торган дөнья.**
**Ямьле таңны сәламләп**
**Бөдрә каен яфраклары лепердәшеп куя...** ***А.Шәгәрәева***



**Безгә азык биргән Җир-ананы**
**Кыерсытмыйк кызу чагында.**
**Җирне талап, түләмичә әҗерен,**
**Калмыйк тагын котлык базында.**

***Г.Насыбуллина- Нигъмәтҗанова***





- Г.Шәгәрәева

**Мин чәчәкләрне яратам**
**Алар шундый хуш исле.**
**Һәммәсе дә бик матур**
**Төрледән төрле төсле.**

**Һәрберсенең исемнәре**
**Үзләренә килешә.**
**Табигатьнең гүзәллеге -**
**Чәчәкләр ул минемчә...**
***А.Шәгәрәева***







А.Әхмәтҗанова









А.Әхмәтҗанова








Н.Габбазов




Н.Габбазов
16.06.2010


Н.Габбазов

# Матурлыкны югалтмыйк!

*Саклагыз табигатьнең*
*Урманнарын,кырларын.*
*Һәр яз саен ишетерсез,*
*Моңлы кошлар сайравын.*
*Алар да бит ярааталар*
*Табигать чисталыгын.*
*Дөнья чиста, матур булса,*
*Ни кирәк безгә тагын.*
*Утыртыйк без каеннар,*
*Юкәләр, алмагаялар.*
*Шушы агачларга кунып,*
*Сайрарлар сандугачлар.*
*Нинди күңелле була,*
*Сандугач сайраганда.*
*Рәхәтләнеп ял итәргә,*
*Табигать кочагында.*
*Матурлыкны югалтмыйк, дисәк*
*Табигатькә кул сузмыйк.*
*Кошларга һәм хайваннарга,*
*Гел игелекле генә булыйк.*

*Г.Хәсбибуллина*




Н.Габбазов

# Көзге яңгыр

Тышта көзге яңгыр ява
Табигать елый сыман.
Күктә зәңгәр болыт йөз
Иртәдән төште томан.
Көзге яңгыр ява-ява.
Бөтен җирне чылата.
Бу яңгырның челтерәв
Үземне дә елата.
Табигать елап озата.
Кошларын җылы якка.
Табигатьне моңсулаты
Килде көз безнең якка.

А.Шәгәрәева

# Авылда көз




Р.Кашапов

Н.Габбазов






Н. Габбазов




Н.Габбазов





- Г.Шәгәрәева





Н. Габбазов





# Урта Йорткүл авылы китапханә
# Төзүче: Әхмәтҗанова А.М.

